…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!

# Караш

1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.
№ 1 2015. Октябрь - ноябрь
«НӘШРИЯТ ЭШЕ» түгәрәге

## 5 нче октябрь – Халыкара укытучылар көне.

**Нинди генә теләк теләсәк тә,**
**Бик аз булыр кебек тоела.**
**Күпме игелекләр эшләдегез**
**Кешеләргә гомер буена.**
**Артта калган якты эзегезгә,**
**Кылган эшегезгә таң калып,**
**Алгы көнегездә дә хөрмәт тоеп,**
**Яшәгез сез җирдә шатланып.**
**Дөнья тыныч, еллар имин булсын,**
**Йортыбызда булсын бәрәкәт.**
**Җан җылыгыз, саф күңелегез өчен,**
**Барыбыздан сезгә мең р ә х м ә т!**



Хөрмәтле укытучыларыбыз!Сезне һөнәри бәйрәмегез белән тәбрик итәбез! Безгә белем биргәнегезгә, безне түзгәнегезгә ЗУР РӘХМӘТ! Ачуландырганнарыбыз өчен, шуклыкларыбыз өчен, безнең хакта кире яңармаячак нервыларыгыз өчен, зинһар, гафу итегез безне. Сез безнең күңелдә һәрвакыт мөлаем, сабыр, итагатьлелек үрнәге булып торасыз.

## Хуш киләсең, Көзбикә!

Октябрь ае күңелләрдә шаулап-гөрләп үткән көзге бал кичәләре белән истә калыр. Әлеге күркәм традиция елдан-ел байый, эчтәлеклерәк була бара. Һәр ел саеннинди дә булса яңалык өстәлеп. Безне гаҗәпләндерә, шатландыра. Әнә быел да 10 нчы сыйныф егетләренең чыгышларын тиз генә онытa алмабыз әле, шулай бит! Шунысы гына кинәле булды, быел Кыш бабай Көзбикәне никтер ашыктырды әле, аяк астында сары яфраклар урынына, ап-ак кар шыгырдый... (көз бәйрәменнән күренешләр)





ОКТЯБРЬДӘ... олимпиадаларның мәктәп туры тәмамланды. Әлеге турда җиңүче укучыларыбызга мәктәп данын район турында яклау өчен күп көч куярга туры киләчәген аңлап, аларга уңышлар телибез. (Кемнәр ничек чыгыш ясавы турында мәгълүмат мәктәп сайтында урнаштырылган)

ОКТЯБРЬДӘ... мәктәптә күп кенә түгәрәкләр эшли башлады. Укучыларга үз сәләтләрен тагы үстерүгә мөмкинлекләр ачылды, кулдан ычкындырмагыз!!!

ОКТЯБРЬДӘ... мәктәптә бассейн эшли башлады. Ниһаять, рәхәтләнеп йөзәчәкбез!!!

НОЯБРЬДӘ... олимпиадаларның мәктәп туры башланып китте. Инде уңышларыбыз да бар!!!

НОЯБРЬДӘ... Кэс-Баскет ярышларының мәктәп туры узды. Безнекеләр – БЕРЕНЧЕ!

НОЯБРЬДӘ... Чистай шәһәрендә булып узган көрәш ярышында безнең егетләр беренчелекне бирмәде.

**Алтын Каләм – хыялларны чынга ашыра... (“Алтын Каләм” -Республика Фестиваленнән алган тәэсирләр.)**

... Быел булмады ахры, фестивальнең көннәре якыная, ә исемлек әле дә юк инде дип борчылып әллә нишләп беттем! Шунда, капка төбендә утырганда, бер таныш булмаган номер шалтыратмасынмы? Сикерә-сикерә өйгә чаптым...

...Фестивалебез 23нче июньнән старт алды. Гадәттәгечә, ачылыш тантанасында күккә шарлар очырдык. Мин фестивальгә быел өченче тапкыр катнашучы булып барам.





**Беренче көннән(23.06)** үк безне мастер-классларга чаптырып йөртә башладылар. Тегеңә кер, монсына, үлерсен анда. Ләкин шулай чабып йөрүләре үзе бер кызык бит ул. Мин “каләм”дә! Мин “каләм”дә чабып йөрим. Моны теләмәгән иденме син? Әлбәттә! “Каләм”гә Рания БАРЫСЫНА ДА өлгерергә дип килә дә инде ул. Бер мастер-класснта Евгения Овчаренко шундый кызык, уйландыргыч фикерләр әйтте. Шуларның берничәсе: “Бераз юләр була бел!”, “Юк – ул җавап түгел”, “Бөтен дөнья – кечкенә генә авыл ул. Алар җепләрдән торалар, җеп өзелдеме, бетте баш!”.



**Икенче көнне(24.06)** безне КФУның музеена һәм Казандагы иң зур стадионнарның берсе “Казан Арена”га алып бардылар. Музейдагы экспанатларны күрсәге-е-е-ез, бер гасыр артка киткән буласыз. Шулай булды да инде ул, XIXгасырда булуы, Толстойның өстәле артында утыруы, үзе бер тарих. Ә “Казан Арена”да безгә журналистларның “база”ларын күрсәттеләр. Бөтендөнья су ярышлары чемпионаты вакытында журналистлар кайда эшлиячәк, кайда бар мәгълүматны туплаячакларын сөйләделәр. Бик тә стадионга керәсе килгән иде дә, ни кызганыч, анда төзелеш бару сәбәпле, безне кертмәделәр. “Волга”га кайткач, “Ватаным Татарстан” гәҗитенең баш мөхәррире Сәфәров Миңназыйм белән очрашу булды.



**Өченче көнне(25.06)** “Беренче канал”ның мәгълүмати программалар дирекциясе махсус корреспонденты Тимур Сиражиев белән очрашу булды. Ул безгә журналистның уңай һәм тискәре якларын санап китте, шуңа да карамастан,журналистика ул әйбәт профессия һәм аның белән эшләргә кирәк диеп күндерде. Ә белеме буенча Тимур абый журналист түгел икән. Аңа кадәр ТНВ телерадиокомпаниясенең “Яшьләр online” тапшыруын алып баручы – Данил Сафәров белән очрашу узды. Ул да безгә бар төр журналистиканы аңлатты. Яхшы журналистка бар төр журналистика ярый. Аның берничәсе белән эшли беләсең икән инде, син ДАҺИ!!

**Дүртенче көнне(26.06)** мин аеруча яраттым, чөнки безгә Дәүләт советының председателе Фәрит Мөхәммәтшин килде. Аның белән аралашуга сәгать кенә бирелсә дә, без бу сәгатьне бушка уздырмадык. Төрле сораулар бирдек. Фәрит абыйның графигы тыгыз булу сәбәпле, безнең сорауларга ул җавап бирергә өлгермәде, китеп барды!



Әле шуның белән генә кызыклы мизгелләр бетмәде. Безнең өчен оргкомитет махсус “пеналы вечеринка” оештырды! Ул каләмчеләрнең шул күбектә аунаганнарын күрсәге-ез, анда мин дә бар идем, рәхәтләндек кенә. Көне буе шунда ятыр идек тә, тагы мастер-класслар башланды. “Intertat.ru” электрон газетасы баш мөхәррире Илназ абый Фазуллин белән очрашу булды. Ул

гәҗит белән бергә спорт яңалыкларын тыш һәм район газеталарының кушымталарын да алып бара икән.



**Бишенче көнне(27.06)** без Горький исемендәге паркта булдык. Ни өченме? Гади генә экскурсия түгел,ә бәйрәмдә. Яшьләр көненә багышланган чарада катнашып кайттык, бәйрәм иттек. Монда Әтнәдә сез генә бәйрәм итмәдегез ул. Кулларыбызга шарлар тоттырдылар, күтәренке кәеф бирделәр.

Парклардан кайткач, мастер-классlар беткәч, безнең төркемгә җырчы Илназ Сафиуллин килде! Ах, бу сәләтле абыйдан эреп төшә идем инде мин. Безнең сорауларның барсына да җавап биреп бетерде ул. Җитмәсә гитарада да уйнап, җыр башкарды, автографлар да бирде.

**Алтынчы көн(28.06)** безнең ял көне. “Мафия” уйнап рәхәтләндек инде.

**Соңгы көн(29.06)** килеп тә җитте. Бу атна бик тиз үтте минем өчен. Әле генә автобуста хыялланып бара идем, ә монда бүләкләү дә килеп җите. 11ләрдә без “Волга”дан Дуслык йортыначагып киттек.

Менә бүләкләү тантанасы да килеп җитте. Башта төрле номинацияләрдә җиңүчеләрне котладылар. Тегендә Рания Газимзянова димәсеннәрме? Күзем шакмак булды. Мин сәхнәгә күтәрелдем. Мине дә, калганнарны бүләкләделәр дә, үз урыннарыбызга утырттылар.




P.S. Мин “Алтын Каләм”нең XX фестивалендә булдым. Стаж алдым, дуслар таптым һәм бары күтәнке генә кәеф. Минемчә, максатыма ирештем бугай инде. Элек журналистиканың нәрсә икәнен белмәсәм дә, хәзер язасым гына килеп тора. Ә “Алтын Каләм”дә үткән көннәр сагындырааааа....



## Хәйләсез дөнья файдасыз.

Бер йортта, кайсыдыр бер заманда яшәгән ди, булган ди бер әтәч гаиләсе. Бу гаилә зур булган, чөнки бу әтәчнең хатыннары гына да 15 ләп икән. Ләкин Әтәчның хатыннары Бибитавыкҗамаллар бар рәхәткә шөкер итеп яши белмәгәннәр. Һәр көнне үзара талашалар, кай көннәрдә бу талаш сугышка да әйләнә икән. Талашның төп сәбәбе – кайсы тавык иң матуры, иң булганы, ягъни Әтәчкәйнең иң яратканы икәнне ачыклау. Ярар. Көннәр үтә торган, Әтәч бу шау-шудан тәмам туйган. Бер көнне йортта кабат тавыш купкач, ул койма башына менеп утырган икән. Шулай моңаеп утырганда, аның башына бер гаҗәеп идея килгән: “Тавыккайларым, җаныкайларым, барыгыз да бик уңган, барыгыз да бик булган, ләкин мин йөзә белгән тавыкбикәне генә яратам шул. Кем иртәгә әнә шул бакча башындагы инешне йөзеп чыга, шул сөекле бикәм була! Йөзә алмаучылар башка авызын да ачмый!”- дигән ул. Тавыклар шым булганнар. Башларына кайгы төшкән. Тик бер тавык кына – Бибичуар гына шыпырт кына инеш ягына киткән. Ары барган, бире килгән, шундый кызык нәрсә күргән: шунда коенып уйнап яткан малайлар аякларына әллә ни кияләр дә, сызгыртып йөзеп китәләр икән! Әнә үрдәкләрнең үз аягы да шундый нәрсәгә бик охшаш. Бер аларга, бер үзенең аякларына карап уйга баткан Бибичуар. Һәм...

Иртә белән Әтәч үз командасын ияртеп инешкә киткән. Ләкин бер тавык та суга керергә базмый икән. Ә Бибичуар тиз генә яр буенда үсеп утырган үги ана яфракларын ике катлап аякларына бәйләгән дә суга сикереп тә төшкән. Башка тавыкларның: “Титибаш, батасың ич!” – дигән сүзләренә исе дә китмичә, башын горур күтәреп йөзеп тә киткән. Әтәч аның кыюлыгына шаккаткан, аны иң яраткан хатыны дип игълан иткән. Менә шулай, кайвакытта күзәтүчән һәм хәйләкәр булсаң, уңышка ирешәсең. (5 нче сыйныф. Мухаметзянова Эвелина)

**Мин кулыма тәүге кабат каләм алам.**

## НИҺАЯТЬ! НИҺАЯТЬ!!НИҺАЯТЬ!!! Без моны күптән көттек!!!

**Инглиз теленнән уздырылган Бөтенроссия олимпиадасының муниципаль турында безнең мәктәп командасы искиткеч уңышларга иреште: берьюлы өч җиңүче! Афәрин! Мәктәбебезнең данын Республика турында да яклап, уңышларга ирешүегезне телибез!!!**

There is no doubt that learning foreign languages is quite necessary nowadays because we live in a global village and everyone sees signs or words written in foreign languages everywhere around.

We can meet them in shopping malls, stations, airports or just on the labels of goods that we usually buy in local markets. So my students consider that well-educated person should be able to communicate with foreigners in English. According to this statement they try to do their best on learning English. Some of them usually take part in different contests or Olympiads on English and gain first prizes. They are hardworking and motivated students. My congratulations to all winners of recent Olympiad, I wish I had steady brilliant results of my students in following years. Try to have your chance in a million and do your best to study well. Practice makes perfect.



6 нчы сыйныф укучысы
Сафиуллина Зөһрә



10 нчы сыйныф укучысы
Шәйхетдинов Илшат



8 нче сыйныф укучысы
Гыйльманова Элиза

**МЕНӘ УЛ БЕЗНЕҢ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕБЕЗ!!!**

## *БУ ТАРИХКА ШУЛАЙ КЕРЕП КАЛГАН*

*(Лашман авылының үзенчәлекле лексик байлыгы рубрикасына)*

Һәр төбәкнең үзенә генә хас үзенчәлекле сөйләм теле бар. Аның диалектлар, сөйләшләр диләр. Бу сөйләшләр бер-берсе белән фонетик, морфологик, синтаксик үзенчәлекләр белән аерылып торалар. Һәр сөйләшнең үзенә генә хас фразеологизмнары да бар, алар бу сөйләшләрнең йөзек кашлары күк кабатланмас лексик хәзинә булып торалар. Кызганыч, әлеге хәзинәгә тулысынча ия булган өлкән буын сафы сирәгәя бара, алар белән бергә лексик хәзинәбез дә онытыла бара. Безнең буын әдәби әсәрләрдә, әдәби сөйләмле тапшыруларда тәрбияләнә. Җирле сөйләмебезне бу күренеш кысырыклый бара.

Әбием белән сөйләшкәндә ул әйткән гыйбарәләрне еш кына аңламыйча кабат сорыйм. Ул миңа аларны иркенләп аңлата, сөйләмебезгә ничек килеп керү тарихын сөйләп бирә. Баксаң, авылыбыз җирлегендә генә дә күпме үзенчәлекле лексик хәзинә ята икән! Аларны тупларга, өйрәнергә, алдагы буыннарга әманәт итеп тапшырырга кирәк, чөнки аларда безнең авылыбызның тарихы, кызыклы шәхесләре.

ҮЛМИ ДӘ, ҮСМИ ДӘ... Бик нык гайрәтне кайтара торган, озакка сузылган эшкә карата әйтелә / *Авылыбызда бер гаиләдә өч бала – ике кыз 1 малай тәрбияләнә. Дүртенчегә бәби алып кайталар. Яз ахыры. Авылда эш күп. Әтиләре эшне болай бүлә: малай абзарларны чиста тотарга да сыерны көтүгә куып каршыларга: икенче кызга идән себерергә дә каз бәпкәләрен карарга; олы кызга бәбине карарга. Җәй ахырларында бу кыз, көннәр буе уйнарга да чыгалмыйча бәби карый, күрше әбисе янына бала арбасы төртеп килеп утыра да: " Сыерны куасың да көн буена тынасың, бәпкәләр дә үсеп елга буена китте. И әби, бу бит НИ ҮСМИ, НИ ҮЛМИ..." дип елап җибәрә.* /

УРМАНГА КАРАГАН ИДЕМ ШУЛ Кирәкмәгән шаһитлыктан качу өчен әйтелә торган гыйбарә. / *Авылның көньягындагы кырда бер төркем колхозчы хатыннар үзләренә бүлеп бирелгән кишәрлекләрендә чөгендер кыралар. Авыл кырыендагы Катнаш азык заводы складыннан шикле машиналар чыгып китүен күреп калалар. Берсен-берсе уздырып сөйлиләр. Кайткач беләләр, складны талаганнар. Милиция килә, апалардан сорау ала башлый. Барысы да узышып-узышып сөйли. Бары бер апа гына "И энем, мин күрмәдем, УРМАНГА КАРАГАН ИДЕМ ШУЛ", - ди. Тегеләр ярты кышка кадәр өч көнгә бер я судка, я күрсәтмә бирергә район үзәгенә йөргәндә, бу апа чөгендерен алып бетерә.*/

**"Караш" газетасының әлеге саны өчен җаваплы: Газимзянова Р. Ф.**
**Хәбәрләшү өчен телефон: 9270444015**